КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 25 апрель г.Казань № 327

Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2018 – 2024 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасының «Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны субсидияләү» чарасын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 24 сентябрь, 873 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 24 сентябрь, 873 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында».

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 25 апрель, 327 нче
карары белән расланды

Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары нигезендә эшләнде һәм Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр) формасында дәүләт ярдәме күрсәтү максатларын, шартларын һәм механизмын билгели.

1.2. Бу Тәртиптә кулланыла торган төп төшенчәләр:

вәкаләтле орган – Татарстан Республикасы территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү өлкәсендә дәүләт тарафыннан җайга салуны гамәлгә ашыручы, бюджет акчасы белән баш эш итүче сыйфатында булучы, бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары бу Тәртипнең 1.4 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы;

вәкаләтле оешма – вәкаләтле орган тарафыннан бу Тәртипнең 1.4 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен вәкаләтле органга билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм тиешле финанс елына җыелма бюджет исемлеге белән күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә ирештерелгән бюджет акчасын алучы сыйфатында бюджет законнары нигезендә булучы «Татарстан Республикасының Кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары – «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән шартлар нигезендә кече предприятиеләргә, шул исәптән микропредприятиеләргә һәм урта предприятиеләргә караган, мәгълүматлары кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрына кертелгән хуҗалык итүче субъектлар (юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр);

гариза – бу Тәртип таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән, субсидия алу өчен

гариза бирүче яки ышанычнамә нигезендә аның тарафыннан вәкаләтләр бирелгән зат тарафыннан вәкаләтле оешмага тапшырыла торган документлар;

килешү – субсидия алучы белән вәкаләтле оешма арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма буенча төзелгән субсидия бирү турында шартнамә;

гариза бирүчеләр – 2020 елның 1 марты торышына Техник җайга салу һәм метрология буенча федераль агентлыкның 2014 елның 31 гыйнварындагы 14-С номерлы боерыгы белән расланган Икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы бүлекләре нигезендә эшчәнлекнең төп төрен гамәлгә ашыручы (ОК 029-2014) (КДЕС Ред.2)), Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу нәтиҗәсендә килеп туган хәлнең начараюы шартларында иң күп зыян күргән Россия икътисады тармаклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы карарында күрсәтелгән төп эшчәнлек төрләреннән тыш, гариза бирү аеннан алдагы ай эчендә алынган керем 2019 ел өчен уртача айлык керем белән чагыштырганда 30 проценттан артыкка кимегән, шулай ук гариза бирү вакытында эш урыннары санын 2020 елның марты белән чагыштырганда 90 проценттан да ким булмаган күләмдә саклап калган, вәкаләтле оешмага гариза биргән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары;

кредит шартнамәсе – гариза бирүче белән Россия Федерациясе Үзәк банкының (Россия Банкының) махсус рөхсәте (лицензиясе) булган Россия кредит оешмасы арасында әйләнештәге акчаны тулыландыруга, төп чараларны сатып алуга, инженерлык инфраструктурасын, җитештерү биналарын, төзелмәләрен, корылмаларын төзүгә (реконструкцияләүгә), шулай ук инвестиция проектларын тормышка ашыруга төзелгән, гариза бирү көнендә гамәлдә булган шартнамә;

субсидия алучы – субсидия бирү турында карар кабул ителгән гариза бирүче.

портал – кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм чараларын электрон рәвештә алу максатында гариза һәм документлар бирү өчен кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының хокукларын тормышка ашыру өчен билгеләнгән, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://фасттрек.рф адресы буенча урнашкан белешмә-мәгълүмат ресурсы;

гаризалар кабул итү реестры – вәкаләтле оешмага кергән гаризаларны теркәү өчен тегелгән, сан сугылган китап. Гаризалар кабул итү реестры формасы вәкаләтле оешманың тиешле боерыгы белән раслана

1.3. Субсидияләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацияле икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацияле икътисады» дәүләт программасының «2018 – 2024 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасының «Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны субсидияләү» чарасын гамәлгә ашыруга тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

1.4. Субсидияләр гариза бирүчеләргә 2020 елның 01 апреленнән алып 2020

елның 30 сентябренә кадәр теләсә кайсы ай өчен фактта җитештерелгән һәм документаль расланган чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында, әйләнештәге акчаларны тулыландыруга, әлеге Тәртипнең 1.5 пунктында күрсәтелгән чыгымнардан тыш, төп чараларны сатып алуга, инженерлык инфраструктурасын, җитештерү биналарын, төзелмәләрне, корылмаларны төзүгә (реконструкцияләүгә), шулай ук инвестиция проектларын гамәлгә ашыруга кредит шартнамәләре буенча процентларны түләүгә бәйле рәвештә бирелә.

1.5. Субсидияләр бирелми:

счетта акча җитмәгәндә бирелгән кредитлар буенча чыгымнарны кайтаруга (овердрафт);

чит ил валютасы чараларын сатып алуга.

## II. Гариза бирүчеләргә карата таләпләр

2.1. Субсидия килешү төзергә планлаштырыла торган ай алдыннан килгән айның 10 ысына түбәндәге шартларга туры килүче гариза бирүчегә бирелә:

2019 елның 1 декаберннән дә соңга калмыйча Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә теркәлгән;

мөрәҗәгать итүче – юридик зат үзгәртеп кору, бетерү процессында тормый, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, аның эшчәнлеге Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында һәм (яисә) Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексында каралган тәртиптә туктатылмаган, ә мөрәҗәгать итүче – индивидуаль эшмәкәр буларак эшчәнлеген туктатмаган;

чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган салым салуның ташламалы салым режимын бирә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләре үткәргәндә мәгълүмат ачу һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган (офшор зоналар) чит ил юридик затларының катнашуы өлеше тулаем алганда 50 проценттан артып киткән россия юридик заты булып тормаган,

бу Тәртипнең 1.4 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмаган;

Татарстан Республикасы бюджетыннан элегрәк алынган субсидиягә, бюджет инвестицияләренә, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә алынганнарга бәйле рәвештә, башкарылмаган йөкләмәләре булмаган;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне һәм Татарстан Республикасы бюджеты алдында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмаган;

акциз алынырга тиешле товарлар җитештерү һәм сату, шулай ук файдалы казылмалар (гомумтаралган файдалы казылмалардан тыш) чыгару һәм реализацияләү гариза бирүченең бер эшчәнлек төреннән булмаган;

кредит оешмасы, иминият оешмасы (кулланучылар кооперативларыннан тыш), инвестиция фонды, дәүләткә карамаган пенсия фонды, кыйммәтле кәгазьләр

базарында профессиональ катнашучы, ломбард булмаган;

продукцияне бүлешү турындагы килешүләрдә катнашучы булмаган;

уен бизнесы өлкәсендә эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашырмаган.

## III. Гариза составында документлар исемлеге

3.1. Субсидия алу өчен гариза бирүче вәкаләтле оешмага түбәндәге документлар белән гариза тапшыра:

бу Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтада бирелгән форма буенча субсидия бирүгә гариза;

гамәлгә кую документлары, шәхесне таныклаучы документ (шәхси эшмәкәрләр һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары башлыклары өчен) күчермәләре;

кредит оешмасы тарафыннан расланган гамәлдәге кредит килешүе күчермәсе;

гариза бирүче счетларыннан кредиттан файдаланган һәм аны түләү өчен кредит оешмасы раслаган процентларны түләүне раслый торган өземтә;

кредиттан файдаланган өчен исәпләнгән процентларны түләүне һәм аны түләп бетерүне раслый торган, кредит оешмасы тарафыннан расланган гариза бирүченең счетларыннан өземтәләр;

кредит оешмасының әйләнештәге акчаны тулыландыруга, төп чараларны сатып алуга һәм (яки) инженерлык инфраструктурасын, җитештерү биналарын, төзелмәләрен, корылмаларын төзүгә (реконструкцияләүгә) һәм (яки) инвестиция проектларын тормышка ашыруга кредит шартнамәсе буенча бирелгән кредитны максатчан файдалану турындагы бу Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча белешмә кәгазе;

кредит оешмасының кредит килешүе буенча фактта түләнгән процентлар суммасын исәпләү, 2020 елның 01 апреленнән кредит оешмасына мөрәҗәгать иткән датага Россия Банкы тарафыннан билгеләнгән төп ставка күләмендә;

Россия Федерациясе Үзәк банкының (Россия Банкы) махсус рөхсәте (лицензиясе) булган Россия кредит оешмаларында гариза бирүченең ачык исәп-хисап счетлары турында салым органы белешмәсе;

Әлеге Тәртипкә 3 нче кушымта нигезендә форма буенча булган ачык исәп-хисап счетларының торышы турында кредит оешмалары белешмәләре;

2020 елның мартына һәм соңгы хисап көненә СЗВ-М формасы буенча гариза бирүченең (мондый мәгълүматларны Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә бирүче затлар өчен) иминләштерелгән затлары турында мәгълүматлар күчермәләре (пенсия фонды органнарының кабул итү турындагы тамгасы белән яисә электрон санлы имза куелган хисап документларын электрон рәвештә кабул итү һәм тикшерү турындагы документлар белән тапшырыла);

әлеге Тәртип кысаларында вәкаләтле затның гариза бирергә һәм гариза составына керүче документларга имза куярга хокукы булуын раслый торган, Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә (вәкаләтле зат тарафыннан гариза бирелгән очракта).

3.2. Гариза бирүче шулай ук вәкаләтле оешмага тиешле тәртиптә расланган түбәндәге документларның күчермәләрен тапшырырга хокуклы:

гариза бирү көненә карата бирелгән һәм Россия Федерациясе законнары белән

билгеләнгән тәртиптә таныкланган Юридик затларның (индивидуаль эшкмәкәрләрнең) бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

гариза бирү көненә карата бирелгән һәм Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә таныкланган Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрыннан өземтә.

Мөрәҗәгать итүче әлеге пунктта күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, вәкаләтле оешма әлеге мәгълүматларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә ала.

3.3. Чит телдә язылган документларны гариза бирүче аларны билгеләнгән тәртиптә таныкланган рус теленә тәрҗемәсе белән тапшыра.

3.4. Тапшырыла торган мәгълүматларның дөрес булмавы өчен гариза бирүчеләр Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

3.5. Әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән порталның тиешле бүлекләре эшли башлаганчы, гариза кәгазьдә бер нөсхәдә тапшырыла.

3.6. Порталның тиешле бүлекләре эшләгән очракта гаризалар кәгазьдә яки электрон формада портал аша кабул ителә.

## IV. Субсидия алуга документлар әзерләү

4.1. Субсидия алу өчен згариза бирүче вәкаләтле оешмага бу Тәртип таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән гариза бирә.

4.2. Гариза биргәндә тапшырыла торган барлык документлар төгәл басылган һәм һәр пункты буенча тутырылган булырга тиеш (мәгълүматлар булмаган очракта, сызык куела). Чистартып язулар һәм төзәтүләр рөхсәт ителми (мөһер (мөһер булганда) белән беркетелгән һәм вәкаләтле затның (юридик затлар өчен) имзасы яки үз кулы белән (индивидуаль эшмәкәрләр өчен) таныкланган төзәтүләрдән тыш.

Гаризаның барлык битләренә сан сугылган булырга тиеш. Гариза тегелгән булырга тиеш һәм гаризаның иң соңгы битенә, битләрнең гомуми санын күрсәтеп, гариза бирүченең яки вәкаләтле затның имзасы һәм гариза бирүченең мөһере белән (мөһер булганда) таныкланган булырга тиеш. Электрон рәвештә тапшырыла торган документлар сканерлау чаралары ярдәмендә тулы төстә тапшыру режимында булдырылырга һәм мөрәҗәгать итүче яисә вәкаләтле зат тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә идентификация һәм аутентификация бердәм системасында авторизация юлы белән имзаланырга тиеш.

4.3. Гаризаны әзерләү буенча барлык чыгымнарны гариза бирүче башкара.

## V. Гаризаларны кабул итү һәм карап тикшерү

5.1. Гаризалар вәкаләтле оешма тарафыннан кабул ителә.

Гаризаларны кабул итү вакыты турындагы мәгълүмат вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында гаризаларны кабул итә башлаган көнгә кадәр эш көннәрендә исәпләнелгән өч көн эчендә бастырып чыгарыла.

Әлеге Тәртип турында һәм Әлеге Тәртип нигезендә тутырылырга тиешле

документларның формалары турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә вәкаләтле орган сайтында урнаштырыла.

5.2. Гариза вәкаләтле оешма тарафыннан кергән көнендә, аның керү көнен һәм вакытын күрсәтеп, гаризаларны кабул итү реестрында теркәлә.

5.3. Гаризаны теркәгән көннән эш көннәрендә исәпләнгән 15 көн эчендә вәкаләтле оешма гариза бирүчене һәм алар тапшырган документларны бу Тәртип белән билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәүгә тикшерә һәм вәкаләтле органга субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен вәкаләтле орган тарафыннан расланган форма буенча тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат җибәрә.

Әгәр дә гариза бирүче бу Тәртип таләпләренә туры килсә, ләкин бүлеп бирелгән бюджет ассигнованиеләре лимитлары бу Тәртипнең 6.3 нче пункты нигезендә исәпләнгән күләмдә субсидия бирү өчен җитәрлек булмаса, вәкаләтле оешма, гариза бирүчегә бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән вакыт чыкканга кадәр биш календарь көненнән дә соңга калмыйча, бу Тәртипкә теркәлгән 4 нче кушымтада бирелгән форма буенча бюджет ассигнованиеләре лимитлары җитәрмәү һәм бюджет йөкләмәләре лимитларының калган өлеше күләмендә субсидия алу мөмкинлеге булу турында хәбәрнамә җибәрә. Гариза бирүче тарафыннан бюджет йөкләмәләре лимитларының калган өлеше күләмендә субсидия алуга риза булуы турында карар кабул ителгән очракта, гариза бирүче бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән вакыт чыкканга кадәр вәкаләтле оешма адресына бу Тәртипкә теркәлгән 5 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча ризалык җибәрә.

Бу пунктның икенче абзацында күрсәтелгән вакыт эчендә язма ризалык бирелмәгән очракта, субсидия алу хокукы гаризаларны кабул итү исемлеге нигезендә чират буенча килүче гариза бирүчегә бирелә.

4. Вәкаләтле орган вәкаләтле оешмадан мәгълүмат алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә вәкаләтле орган тарафыннан расланган форма буенча субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Вәкаләтле оешма гариза бирүчегә, вәкаләтле орган тарафыннан расланган форма буенча вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча, субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә җибәрә.

Субсидияләр гаризаларны кабул итү датасы һәм вакыты буенча беренче булып гариза биргән мөрәҗәгать итүчедән башлап, әлеге Тәртип таләпләренә туры килә торган мөрәҗәгать итүчеләргә бирелә.

5.5. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

гариза бирүче тарафыннан бу Тәртипнең 3.1 пункты белән күздә тотылган документлар тапшырылмау (тулы күләмдә тапшырылмау);

гариза бирүченең һәм (яки) тапшырылган документларның, аларда бирелгән мәгълүматларның бу Тәртип белән күздә тотылган таләпләргә һәм шартларга туры килмәве;

бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы;

бюджет ассигнованиеләре җитмәүгә бәйле рәвештә, субсидия күләмен киметү

турындагы хәбәрнамәгә җавап итеп, гариза бирүченең бу Тәртипнең 5.3 нче пунктындагы беренче абзацында күрсәтелгән вакыт чыкканга кадәр бу Тәртипкә теркәлгән 5 нче кушымтада бирелгән форма буенча язма ризалыгы булмавы.

5.6. Вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгән мөрәҗәгать итүче аны алудан килешү төзелгәнчегә кадәр баш тартырга мөмкин. Моның өчен гариза бирүче вәкаләтле оешмага субсидия алудан язмача баш тарту тапшыра.

5.7. Субсидия бирүдән баш тартылган гариза бирүче яңа гариза белән билгеләнгән тәртиптә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

5.8. Гаризалар вәкаләтле оешмада саклана. Субсидия бирүдән баш тартылган гариза бирүче үзе биргән гаризаны сорап алырга хокуклы. Сорап алынмаган гаризалар вәкаләтле оешмада 10 ел эчендә саклана. Гаризаларны вәкаләтле оешмада тиешенчә саклауны тәэмин итү мөмкин булмаган очракта, вәкаләтле оешма аларны, Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән килештереп, «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенә җаваплы саклауга түләүсез нигездә тапшырырга хокуклы.

## VI. Субсидия бирү тәртибе

6.1. Килешү субсидия алучы белән вәкаләтле оешма арасында вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән ун эш көне эчендә төзелә.

Килешүдә субсидия күләме; аның максатчан билгеләнеше; түләүләрен гамәлгә ашыру өчен субсидия бирелә торган чыгымнарның юнәлешләре; субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләре; субсидияне күчерү тәртибе; субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисап документларын бирү вакытлары һәм формалары; субсидия алучының вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан субсидия алучының аны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләрне гамәлгә ашыруга ризалыгы карала.

6.2. Субсидияләр вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында субсидия алучы өчен ачылган алучының исәп-хисап счетына акча күчерү юлы белән бирелә.

6.3. Субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$РС_i = \sum П_i - \sum ПС_i,$$

монда:

$П_i$ – бу Тәртипнең 3.1 нче пункты нигезендә тапшырыла торган документлар нигезендә Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнгән i-гариза бирүченең түләнгән процентлары;

$ПС_i$ – бу Тәртипнең 3.1 нче пункты нигезендә тапшырыла торган документлар нигезендә i-гариза бирүченең түләнгән процентлар буенча элегрәк алынган субсидиясе.

і -гариза бирүчегә субсидиянең максималь күләме 1,5 млн. сумнан артмаска тиеш.

6.4. Субсидия бирү нәтиҗәләре булып тора:

субсидия алучыга – юридик затка – субсидия алучының финанс-хуҗалык эшчәнлеген алып баруын дәвам итү, субсидия алучының – юридик затның үзгәртеп кору, бетерү һәм банкротлык процедурасында булу факты булмау, бөлгенлектә (банкрот) дип тану турында гариза булмау;

субсидия алучыга – шәхси эшмәкәр яки крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы өчен – субсидия алучы тарафыннан финанс-хуҗалык эшчәнлеген алып баруны дәвам итү, индивидуаль эшмәкәр яки крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы буларак эшчәнлекне туктату һәм банкротлык процедурасын кертү, бөлгенлектә (банкрот) дип тану турында гариза булмау.

Субсидия алучы субсидияләр бирү нәтиҗәләрен раслау өчен вәкаләтле оешмага әлеге Тәртипнең 6 нчы кушымтасы нигезендә, тиешле документлар кушып, гарантия хаты тапшыра.

Вәкаләтле оешма гарантия хаты нигезендә һәм хисап чорының соңгы датасына юридик затларның (шәхси эшмәкәрләрнең) бердәм дәүләт реестрыннан өземтә соратып алу юлы белән, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләрнең казанышларын бәяләүне гамәлгә ашыра.

Субсидия алган көннән исәпләп чыгарыла торган 30 календарь көн хисап чоры булып тора.

6.5. Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында гарантия хаты субсидия алучы тарафыннан вәкаләтле оешмага хисап чоры тәмамланганнан соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

6.6. Вәкаләтле оешма субсидия алучының нәтиҗәләргә ирешү турындагы хисап нигезендә субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешүләрен бәяли.

6.7. Бирелгән субсидияләр Татарстан Республикасы бюджеты кеременә субсидия алучы вәкаләтле оешманың тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

вәкаләтле орган, вәкаләтле оешма һәм дәүләт финанс тикшерүе органнарының тикшерү фактлары буенча субсидия алучы тарафыннан бу Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән шартлар бозылу ачыкланганда;

вәкаләтле оешмага һәм вәкаләтле органга дөрес булмаган мәгълүматлар биргәндә;

субсидия алучы Татарстан Республикасыннан читтә теркәлгәндә;

хисап чоры нәтиҗәләре буенча субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткеченә ирешмәгәндә.

Вәкаләтле орган һәм финанс тикшерүе органнары бу Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешенә тикшерүне гамәлгә ашыра.

Субсидия алучы тарафыннан субсидия акчасын кире кайтару өчен билгеләнгән вакыт бозылганда вәкаләтле оешма бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән вакытлар тәмамланган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә субсидияне Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә кире кайтару буенча чаралар күрә.

6.8. Почта һәм банк реквизитлары, телефоннарның элемтәгә керү номерлары, гамәлгә куючылар һәм җитәкче затлар составы үзгәргән, салым исәбенә куелу урыны үзгәргән, гамәлгә кую документларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр керткән, кредит шартнамәсе предметы үзгәргән, үзгәртеп оештыру, бетерү, бөлгенлеккә төшү (алучылар – юридик затлар өчен) процессы башланган, индивидуаль эшмәкәр буларак эшчәнлекне туктату процессы башланган (алучылар – индивидуаль эшмәкәрләр өчен) очракларда, субсидия алучы бу турыда вәкаләтле оешмага әлеге вакыйгалар башланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

6.9. Субсидияләрне максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тоту вәкаләтле орган, вәкаләтле оешма, финанс тикшерүе органнары тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә 1 нче кушымта

Форма

## Субсидия бирүгә гариза

| т/с | Күрсәткеч исеме | Гариза бирүченең мәгълүматлары [1] |
|---|---|---|
| 1. | Гариза бирүченең тулы исеме | |
| 2. | ИНН | |
| 3. | КПП | |
| 4. | ОГРН | |
| 5. | ОКПО | |
| 6. | ОКТМО | |
| 7. | Юридик затның урнашу урыны / шәхси эшмәкәрнең (крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгының) яшәү урыны | |
| 8. | Юридик затның фактик адресы / шәхси эшмәкәрнең (крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгының) яшәү урыны | |
| 9. | Дәүләт теркәвенә алу датасы | |
| 10. | Банк реквизитлары, шул исәптән исәп-хисап счеты, корреспондент счеты, БИК | |
| 11. | Җитәкченең телефон номеры | |
| 12. | Вәкилнең элемтәгә керү өчен телефон номеры | |
| 13. | E-mail | |

--------------------------------

[1] Барлык юллар тутырылган булырга тиеш. Мәгълүматлар булмаган очракта, сызык куела.

Бу заявкадагы һәм мин тапшырган теләсә нинди башка документлардагы минем шәхси мәгълүматларымны «Татарстан Республикасының Кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан эшкәртүгә үземнең ризалыгымны белдерәм. «Татарстан Республикасының Кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы шәхси мәгълүматларны системалаштырырга, тупларга, сакларга, анықларга (яңартырга, үзгәртергә), кулланырга, таратырга (шул исәптән өченче затларга тапшырырга), тамгаларга, блокировкаларга һәм юк итәргә мөмкин.

Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибенең II бүлеге белән билгеләнгән таләпләргә туры килүемне, шулай ук гариза составындагы тапшырылган документларның дөреслеген раслыйм.

Гариза бирүче___________/_______________________________________________

(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булганда))

М.У. (булганда)

«__» ________ 20__ел

Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә 2 нче кушымта

Форма

Кредитны максатчан файдалану турында белешмә кәгазе

| Кредит шартнамәсен төзү номеры һәм датасы | Кредит шартнамәсе нигезендә кергән акча суммасы, сум | Кредитны максатчан файдалану | | |
|---|---|---|---|---|
| | | чыгымнар төре (билгеләнеше) | чыгымнар суммасы, сум | тотылган чыгымнарны раслый торган түләү йөкләмәсенең номеры һәм датасы |
| | | | | |

Кредитны ____ елның ______________ендәге ______ номерлы кредит шартнамәсендә күрсәтелгән максатлар өчен файдалануымны раслыйм.

Финанс оешмасы җитәкчесе
(вәкаләтле зат)
___________________/_____________________________________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булганда)

М.У. (булганда)

«__» ________ 20__ ел

Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә 3 нче кушымта

Форма

Исәп-хисап счеты торышы турында
белешмә

Алучының исеме: ________________________________________________

| т/с | Исәп-хисап счеты саны | 2020 елда __________[1] счеты буенча керем, сум | 2019 ел өчен уртача айлык керем, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |

Әлеге белешмә табышның кимүен раслый _______________________
_________________________________________________________________
(юридик затның, шәхси эшмәкәр яки крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы исеме, Ф.И.А.и. (соңгысы – булганда))
исәп-хисап счеты буенча ___________________________________________
(исәп-хисап счеты саны)

2019 ел өчен уртача айлык керем белән чагыштырганда 2020 елга ________________[1] ______ процентка.

Финанс оешмасы җитәкчесе (вәкаләтле зат)
___________________/_______________________________________________
(имза) (фамилия, исеме, атасы исеме (соңгысы – булганда))

М.У. (булганда)

«__» _________ 20__ ел

---

[1]Гариза бирү аена кадәр булган ай.

Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә 4 нче кушымта

Форма

Бюджет ассигнованиеләре
җитмәүгә бәйле рәвештә, субсидия күләмен киметү турында
хәбәрнамә

Бу хәбәрнамә белән Сезгә агымдагы финанс елында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2018 – 2024 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасының «Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны субсидияләү» чараларын тормышка ашыру өчен Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибенең (алга таба – Тәртип) 6.3 нче пункты нигезендә исәпләнгән түбәндәге күләмдә бюджет ассигнованиеләре булмавы турында хәбәр итәбез: ______________(________________________________________________________
_______________________________________________________________) сум ____ тиен.

Тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре лимитларының калган өлешләре нигезендә сезгә бирелергә мөмкин булган субсидия күләме _________________________ (____________________
_________________________________________________________________) сум ____ тиен.

Сездән, заявканы теркәүгә алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 15 көннән дә соңга калмыйча, Тәртипкә теркәлгән 5 нче кушымтада бирелгән форма буенча язма ризалык җибәрүегезне сорыйбыз.

Язма ризалык бирелмәгән очракта, субсидия алу хокукы Тәртип кысаларында заявкаларны кабул итү реестры нигезендә чират буенча килүче гариза бирүчегә бирелә.

Вәкаләтле оешма җитәкчесе

__________________/__________________________________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булганда)

М.У. (булганда)

«__» ________ 20__ ел

Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә 5 нче кушымта

Форма

# РИЗАЛЫК

_____________________________________________________________ нигезендә эш итүче
(юридик затның, шәхси эшмәкәр яки крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы исеме, Ф.И.А.и. (соңгысы – булганда))
___________________________________________________________________________
*(юридик затның исеме, индивидуаль эшмәкәрнең Ф.И.Ат.ис.)*
____________________________________________________________________ йөзендә
*(вазыйфасы, мәнфәгатьләрен яклаучы затның Ф.Ис., ат.ис.)*
___________________________________________________________________________,
*(оешма исеме)*
бюджет ассигнованиеләре җитмәүгә бәйле рәвештә, субсидия күләме үзгәрү турында _____ елның _____________ ендәге(ындагы) _____ номерлы хәбәрнамә нигезендә бюджет ассигнованиеләре лимитларының калган өлеше күләмендә, ягъни ___________________(________________________________________________ ____________________________________________________) сум _________ тиен субсидия бирүгә үземнең *(ризалыгымны/риза булмавымны)* ____________________
*(дөресен язарга)*
белдерәм.

__________________/__________________________________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булганда)

М.У. (булганда)

«__» ________ 20__ ел

Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә 6 нчы кушымта

Форма

Гарантия хаты

Субсидия алучы ______________________________________________________
(юридик затның фамилиясе, исеме, атасы исеме (соңгысы – булганда))
_______________________________________________________________________
шәхси эшмәкәр яки крестьян-(фермер хуҗалыгы башлыгы))
йөзендә
_______________________________________________________________________,
(вәкаләтле затның вазыйфасы, Ф.И.А.ис. (соңгысы – булганда)
Түбәндәгеләр нигезендә эш итүче
______________________________________________,
(устав, ОГРИП таныклыклары, ышанычнамәләр реквизитлары)

әлеге субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешүне гарантияли, аерым алганда:

субсидия алучының финанс-хуҗалык эшчәнлеген алып баруын дәвам итү, субсидия алучының – юридик затның үзгәртеп кору, бетерү һәм банкротлык процедурасында булуы факты булмау, субсидия алучыга – юридик затка субсидияне мөстәкыйль (банкрот) дип тану турында гариза булмау;

субсидия алучы тарафыннан финанс-хуҗалык эшчәнлеген алып баруны дәвам итү, шәхси эшмәкәр яки крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы буларак эшчәнлекне туктату һәм банкротлык процедурасын кертү, субсидия алучы – индивидуаль эшкуар яки крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы өчен мөстәкыйль (банкрот) дип тану турында гариза булмау.

Әлеге хатка хисап чорында финанс-хуҗалык эшчәнлеген алып баруны раслаучы документ (кредит оешмасы раслаган шәхси исәп буенча өземтә, яисә субсидия алучы раслаган түләү документларының күчермәләре яисә финанс-хуҗалык эшчәнлеген алып бару фактын раслаучы башка документ) теркәлә.

___________________/______________________________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасы исеме (соңгысы – булганда))

М.У. (булганда)

«__» ________ 20__ ел

_____________________________